*Галимә Кутуева*

# ГАИЛӘ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

Мин үзем Горький шәһәреннән, Горький кызы. Зур гына кебек күренгән гаиләбез егерменче еллар башында бөтенләй кечерәеп калды. Ике апам Мәскәүгә киттеләр, анда тормышка чыгып яши башладылар. Әтием үлеп китте. 1922 елда абыем да үлде. Мин, унҗиде яшьлек кыз бала, авыру әни белән калдым. Ялгыз яшәп булмады, 1922 елда урын өстендә яткан әнине алып, Мәскәүгә, апаларга күчеп килдем. Әни Мәскәүдә бер ун гына көн торды да дөнья куйды. Мин апаларда калдым. Әле берсенә барам, әле икенчесенә. Семьялары зур, балалары күп. Мин өй эшләренә булышам, бала карыйм, тегү тегәм. Укуым өзелде.

Шулай торганда Мәскәүгә Казаннан әтиемнең энесе Мөхәммәтша абзый [1] килде. Мөхәммәтша абзый элек Горький өлкәсенең Грибан авылында мулла булып торган. Аның кызы Сәлимә [2] Горькийда укый иде, бездә торды. Мөхәммәтша абзый үзе дә Горькийга еш килеп йөри иде. Ул килгәч бездә бик күңелле була иде: тавык суела, пәрәмәч пешә. Ул бик җор сүзле, уен-көлке ярата торган кеше иде. Әти белән икәүләп мәчеткә китәләр. Әти сорый:

— Мөхәммәтша, тәһарәтең бармы? — ди.

— Бар, бар, Садыйк абзый, сезнең мәчеткә генә җитәрлек,— ди.

— Мәкаме бик матур, мәчеттәге бөтен кешене җылатты сөйләп,— ди иде әти.

Менә шул Мөхәммәтша абзый 1917 елда коммунистлар партиясенә кергән, Казанда Татселикаттрестта директор булып эшли иде. Минем Мәскәүдәге хәлемне күреп бик борчылып китте. 1923 елда яңадан Мәскәүгә ниндидер съездга килде. Шул чагында миңа әйтте:

— Галимә сеңлем, синең кемең дә юк, сине монда бер сәүдәгәргә кияүгә бирерләр, укый да алмассың, әйдә үзебезгә. Я эшкә керерсең, я укырсың — дип, мине үзе белән Казанга алып китте. Мөхәммәтша абзыйларда тора башладым. Аның кызы Сәлимә Гаделләр компаниясендә иде. Алар — Минский, Гомәр Гали [3], Камал III, Туфан, Кутуй Сәлимәне алырга киләләр дә җыелышып чыгып китәләр. Берсендә Гомәр Гали әйтә:

— Нигә бу чибәр кыз да безнең белән бармый? — ди.

Шулай итеп мин алар компаниясенә керәм. Гадел бик чибәр, яшь, бик оста сөйли, мин гашыйк булып йөри идем. Ләкин Гадел белән минем мәхәббәт тиз генә кушылып китмәде. Башта ул Газзә [4] исемле бер кызга өйләнде. Алар Такташ белән икесе бер кичне өйләнделәр: Такташ — Гөлчәһрәгә [5], Гадел — аның Газзә исемле дус кызына. Такташның «Алсу» поэмасындагы «Ташла әле, Газзә, зачетыңны» дигән юлларда шул кызның исеме кереп калган инде. Алар икесе дә РТЯ-

да[6] укыйлар. Без РТЯда укучыларны санга да санамыйбыз, аларга өстән генә карыйбыз. Ә мин үзем ул чакта медицина училищесында укый идем инде.

Гадел Газзә белән озак тормады. Газзә Мәскәүгә Гөлчәһрә янына китеп барды[7]. Без тагын Гаделне уратып алдык. Мин ул чакта инде Мөхәммәтша абыйлардан киткән идем, Островский урамында дүртенче йорттагы квартираның бер кечкенә бүлмәсендә Хәмдия исемле иптәш кызым[8] белән тора идем. Ул квартирада соңыннан Таҗи Гыйззәтләр яшәде, безнең бүлмә Таҗи абзыйның кабинеты булды.

Гадел безгә еш килеп йөри башлады. Аның да миңа күзе төшкән, күрәсең. Мин сабыр гына, оялчан гына кыз идем. Бик тиз кызара идем. Камал III миннән көлә, нигә син болай кызарасың? — ди.

Ул чагында алар өчесе — Камал III, Кутуй, Сәет Булатов[9] — бергә бер бүлмәдә Кабан күле буендагы Мясной урамында торалар иде. (Сәет Булатов соңыннан артистка Нәфыйга Араповага[10] өйләнде.)

Гаделнең өстәлендә нишләптер гел нашатырлы әнис тамчысы дигән дару тора иде. Буш кич булдымы, без кызлар белән җыелышып, әйдә киттек әнис тамчыларына, дип шунда китәбез. Камал III не барыбыз да ярата идек. Ул — бик күңелле, шук кеше. Кич буе төрле кызык сүзләр сөйләшенә, вакыт тиз уза, алардан бик соң китәбез. Балык базары урамыннан җырлап кайтабыз. Әгәр берәребез үпкәләгән булса, Камал III «ак калфагы яңа каралган чагы»[11] дип җырлап җибәрә дә, үпкәләгән кешенең исемен кушып, «зиһене таралган чагы» дип тәмамлый. Камал III бик матур җырлый иде. Безнең яшьлек шулай бик күңелле үтте.

Гадел бер көнне мине киногa чакырды. «Унион»[12] га «Когда растает снег» исемле картина карарга бардык (ул чагында фильм димиләр иде). Килсәк, сеанс башланырга бер сәгатьтән артыграк вакыт бар.

— Менә яхшы булды, сөйләшәсе сүзләр дә бар. Синең егетең бармы? — ди Кутуй.

— Мәскәүдә бар иде,— дим.— Армиядән кайтты, рабфакта укый.

— Ә хәзер ничек?

— Мин хәзер үк аңа чыгарга риза булмагач, ул өйләнде.

— Шул гынамы? Алайса ярый.

Аннары сөйләшеп йөрдек. Кинодан миңа кайттык. Хәмдүш ул чакта кияүгә киткән иде инде, ялгыз гына

тора идем. Чәй эчтек. Чәй янында нәрсә сөйләшкәнне безне хәтерләмим. Җыен чүп-чар турындадыр инде. Яшь чагында нәрсә сөйләшәсең!

Гадел ул чакта тун киеп йөри иде. Тунының җиңе ертылган иде. Мин аны тегеп бирдем. Гадел көлде:

— Гадәттә мәхәббәт сәдәфтән башлана, безнеке җиңнән башланды,— ди.

Шуннан көн дә килеп йөри башлады. Өстәлдәге кечкенә көзгем өстенә Гаделнең рәсеме кыстырып куелган. Авызына папирос кабып, кепка киеп төшкән рәсеме. Бу Гаделгә бик ошады. Карый да елмая, үзе берни әйтми. Башка егетләр: «Нигә Кутуй рәсеме монда, нигә ул көн дә килә?» — диләр.

1926 елның 26 декабрендә без өйләнештек. Өйләнешү бик гади булды. Гадел ике кәрзинен күтәреп миңа килде. Кәрзиннәрендә китаплар, солдатлар кия торган ише белье иде.

Без өйләнешеп бергә тора башлагач, Такташ һәр кичне безгә килеп йөри торган булды. Мин укыйм, Гаделдән алдарак кайтам. Кечкенә мичемне ягып җибәрәм, бәрәңге әрчеп турыйм да, бер озынча чирәп савытым бар иде, шуның бер ягына суган белән бәрәңге, икенче ягына котлетлар ясап куям (ул чагында кибетләрдә ит фаршы саталар иде, укудан кайтышлый ала кайтам), мич узгач, аны мичкә утыртам, плитәсенә чәйнек белән чәй куям. Бераздан Гадел кайта, аның артыннан ук диярлек Такташ килеп керә. Ул шулай ун көннәр буе көн дә кич безгә килде. Бергәләп чәй эчәбез, сөйләшеп утырабыз. Шул ун көннәр чамасы узгач, Такташ әйтте:

— Сез, дуслар, уйламагыз, ник бу безгә көн дә килә, дип. Сезнең бергә тормыш уңар микән дип карап йөрим...

Үзенең Гөлчәһрә белән тормышы әйбәт түгел иде, шуңа ул безне сынап йөргән.

— Тормышыгыз булыр шикелле, Галимә өй эшен ярата кебек,— диде.

Гадел белән Такташ бик дуслар иде. Яшь булсалар да, бервакыт шулай дип сөйләштеләр. Такташ әйтә: мин алдан үлсәм, син минем каберемә беренче уч туфракны салырсың, син үлсәң, мин салырмын,— диде.

Мин медицина техникумында укый идем. 1927 елның ноябрендә кызыбыз Гөлшат туды. Бала караучы юк, укырга да бала күтәреп йөри идем. Техникумны бетергәч, институтка керәсем килде. Гадел бик каршы булды.

Өйдә торып, аны карап кына яшәвемне теләде. Ә минем укыйсым килде. Гаделнең кыз туганнары барысы да укый, минем дә алардан калышасым килми иде. «Тапшырылмаган хатлар»да минем кичерешләр, теләкләр бик дөрес язылган. 1929—1930 уку елында институтка керер өчен хәзерлек курсларына йөри башладым. Ул чагында медицина институтының директоры Салих Корбангалиев иде. Баламны күтәреп укырга йөргәнемне күргәч, әйтте:

— Галимә сеңлем, азапланып йөрмә, үзем — комиссия председателе, үзем үткәрермен,— диде.

Шулай итеп, мин медицина институтында укый башладым. 1930 елда безнең гаилә өстенә зур бәхетсезлек килеп төште. Гаделгә нахак бәла яктылар. Чинәкәй хаты газетада басылганда [13] мин Гөлшат белән Шелангада дачада идем. Гадел безнең янга килгән, үзенең төсе качкан, нишләргә белми. Мине халык дошманы итеп чыгарганнар, ди. Бөтен вөҗданым белән ант итеп әйтәм: минем күңелем саф, миндә дошманлык юк, ди.

1931 елның февралендә Гаделне җидегәнчелектә гаепләп [14] кулга алдылар. Гадел белән бергә Нәкый Исәнбәтне, Минскийны, тагын кемнәрнедер алдылар. Без, хатыннар, алар белән күрешергә барабыз, ризыклар, башка кирәк-яраклар илтәбез. Аларны тугыз ай тоттылар. Аклап чыгардылар, бер гаеп тә тапмадылар. Ләкин җәмәгатьчелек арасында аларга мөнәсәбәт яхшырмады. Бер җиргә эшкә алмыйлар, беркем исәнләшми, сөйләшми, кайсы күрмәмешкә салына, кайсы, күзгә-күз очрашса да, дәшми үтә. Гадел кайта да башын ике кулы арасына салып утыра. Ул чагында дуслар ташлады, туганнар да бик сирәк киләләр. Килсәләр дә:

— Ишекне бикләгез, без килгәнне кем дә күрмәсен,— диләр.

Гадел көн буе йөреп эш эзләп кайта да башын тотып утыра, сөйләшми. Мин дә аңа сүз дәшәргә куркам.

Авыр чакта яхшы кешеләр ярдәмгә килә. Беркөнне Гадел бик шатланып кайтты. Үзе белән бергә РТЯда укыткан бер укытучыны урамда очраткан икән, ул аңа үзенең ире янына КИКС ка [15] килергә кушкан. Аның ире институтның директоры икән, ирем сиңа сәгатьләр бирәчәк, дигән. Гадел институтта русларга татар теле һәм әдәбият укыта башлады. Бераздан аңа гыйльми секретарь хезмәтен дә бирделәр. Шулай итеп, тормыш уңайлана башлады.

Гадел укытучылык эшен бик ярата иде. Ул 1923—24 елларда ук РТЯда укыта башлаган. Хәтеремдә: партия өлкә комитеты секретарен[16] өенә йөреп татар теле һәм әдәбиятыннан укытты. Берничә ел ҚИҚСта эшләгәч, авиация техникумына эшкә күчте. Анда рус теле һәм әдәбияты укытты. Техникумда бик яхшы, дус коллективка эләкте. Укытучылар да, укучылар да бик яраталар иде үзен. Қутуй дәресен көтеп алалар. Қызлар бар да аңа гашыйк. Гадел аларның берсенә дә игътибар итмәгәч, хатыны нинди соң аның, безнең беребезгә дә карамый, дип гаҗәпләнеп сорыйлар икән.

Бервакыт Гадел өйдә юк чакта биш-алты кыз килеп керде. Үзләре: «Адельша Нурмухаметович дома?» — дип сорыйлар, ә үзләре, юри аның өйдә юк чагын туры китереп, мине карарга дип килгәннәр икән. Миңа моны соңыннан Гадел белән бергә эшләүче укытучылар әйтте. Мин өй киемнәреннән генә идем, чәчем-башым да бик рәтле булмаган, күрәсең. Хатыны гади генә бит, ничек кызларга күзе төшми икән, дип бик аптыраганнар болар. Ә Гадел — бик чибәр, бик яхшы сөйли, шәп оратор иде бит ул. Күп шигырьләрне яттан белә. Қызларны тәмам авызына карата икән. Ә мин аларга әллә ни матур булып күренмәгәнмен.

Гаделнең ярты гомере театрда, артистлар арасында үтә иде. Артистлардан дуслары да бик күп иде. Без бер премьераны да калдырмый йөри идек. Тик театрдан икәүләп өйгә кайтканыбызны хәтерләмим.

— Син бар, кайтып самовар куя тор, ә минем күрәсе кешеләрем бар әле,— дип китә иде.

Самовар дигәннән, чәй эчәргә ярата иде ул. Радиокомитетта бераз диктор булып эшләде. Шунда: «Мин «Сау булыгыз, иптәшләр!» дип әйтеп бетергәнче самоварыңны куя башла, мин кайтканчы кайнап чыгар»,— ди иде.

Театрдан кайткач, төн утырып рецензия яза. Иртән редакциягә илтә. Театрда да бик яраталар иде үзен. Сугыштан ялга кайткан вакытта да концертны алып бару өчен конферансье иттеләр...

Мин уртанчы баламны 1932 елда Мәскәүдә таптым. Мин аны авыр күтәрдем, йөрәк кызуы белән җәфаландым. Қазанда ашау-эчү ягы шәптән түгел иде. Нәкъ практика вакыты туры килде. Практиканы шунда үтәргә дип, Мәскәүгә апаларга киттем. Қызым шунда туды, аңа Кира дип исем куштым.

Гадел Кира дигән исемне яратмады. Ул чакта «Со-

бор парижской богоматери» исемле әсәр буенча куелган картина бара иде, Эсмеральда дигән исем бик модный булып китте. Бервакыт ире белән каенсеңлем килгән иде. Сергей Николаевич әйтә: әйдә бу кыз Эся булсын, ди. Шуннан без аны Эся, Эсенька дип йөри башладык. Аның хәзер ике исеме. Гаиләдә ул — Эся, ә рәсми документларында — Кира.

Мин институтны 1934 елда тәмамладым. 27 апрельдәге приказ белән мине Ютазыга эшкә җибәрделәр. Гадел, китмә, димәде. 15 майда, балаларымны алып, Ютазыга киттем. Өченчесе — бала караучы ятимә кыз иде.

1935 елда мин Ютазыдан Казанга кайттым. Гаделгә әйттем: син яхшы торырга сүз бирсәң генә бергә торабыз, дидем. Әле Казанга кайткач та берничә шундый хәл булды. Мин бит гел эштә. Вакыт белән исәпләшеп торып булмый. Тимер юлда эшли идем. Проводникларны укытасы, төрле консультацияләр, МПВО[17] занятиеләре. Бар да җәмәгать эше тәртибендә. Мин дә үземә тапшырылганны җиренә җиткереп эшләргә өйрәнгән, гаиләгә вакыт аз кала. Бер чакны аерылышу дәрәҗәсенә җиттек. Бүлмә дә эзләп таптым. Гаделгә әйтәм: китәм, дим. Ул әйтә: балаларга әти дә кирәк бит, ди. Уйла, ди. Менә сиңа Большой театрга[18] ике билет, китмәскә уйласаң, шунда кил, ди. Мин уйладым да китмәскә, тагын сынап карарга булдым. Театрга матбугат йорты янындагы проездан[19] төшеп киләм, Гадел театр янында әрле-бирле йөри. Мине күрүгә, каршыма йөгереп килде. Театрда шулкадәр мине кадерләде, урындыгымны кочаклап утырды. Ул көнне инде театрдан бергә кайттык. Шуннан «Тапшырылмаган хатлар» килеп чыкты. Ул безнең үз тормышыбыз нигезендә язылган. Үзенең ничек көнләшүе турында да күп язылган иде, мин җылый-җылый үтенеп ул җирләрен сыздырдым.

Шуннан соң Рөстәм туды, Гаделнең әсәрләрен баса башладылар. Сугыш алдыннан биш-алты ел бик әйбәт, рәхәтләнеп торып калдык.

Тормыш мул түгел иде. Әле дә хәтеремдә: Ютазыдан кайткач, базардан салам көлтәләре алып кайттым да шуларны киндергә төреп матрас ясадым. Гаделнең кышкы пальтосы булганны хәтерләмим, һәрвакыт туңып йөри иде. Чөнки балалар үсә, өч бала бит, укый башладылар. Гадел сугышка киткәндә дә әле безнең караватта шул салам матрас иде.

Гаделнең фронттан килгән хатлары миңа да, балаларга да, хәтта минем белән госпитальдә эшләүче врачларга һәм шунда дәваланучыларга да зур юаныч була торган иде, көч, дәрт бирә иде. Балалар да госпитальгә еш киләләр, чөнки безнең начальник әйбәт кеше иде, карточкаларын алып, балаларга аш бирдерә иде. Менә шунда Гаделдән килгән хатларны җыелып укыйбыз. Аның хатлары бит гаиләгә атап язган интим хатлар төсле түгел. Үзе ил тормышы белән яшәгәч, хатлары да бөтен ил хәлләре турында була иде. Хатлары еш килә иде. 1945 елның апрель азакларында хатлары килми башлагач, бик зур хафага төштем.

Май аенда мине партия өлкә комитетына чакырып алдылар, Бәкер санаториен яралы сугышчылар өчен госпиталь итәргә, шунда баш врач булып барырга тәкъдим ясадылар, Гаделнең дә сәламәтлеге какшаган, аңа да яхшы булыр, диделәр.

Мин 15 майда санаторийны кабул итеп алырга дип шунда киттем. Гаделдән һаман хат юк. Эшләрне бераз җайлагач, ял көненә каршы Казанга кайттым. Андагы танышлардан, дуслардан, туганнардан сорыйм — аларга да хат юк. Бик аптырап, кире Бәкергә киттем. Күп тә үтмәде, минем арттан, мине алырга дип, Казаннан самолет килде, мине Казанга алып киттеләр, анда Гаделнең госпитальдә үлү хәбәрен әйттеләр. Авыр булды, моны ишле бала белән иреннән калган тол хатыннар гына аңлый ала...

Еллар узгач, соңгы вакытта эшләгән урыным — туберкулез диспансерыннан пенсиягә чыккач, яңадан Ютазыга китеп, дүрт ел эшләдем. Шуннан соң 1961 елда улым Рөстәм белән Польшага барып, Гаделнең каберен таптык, аны тиешенчә күтәреп, мәрмәр тактага исемен яздырып кайттык.

1965 елда СССР Язучылар союзы командировкасы белән яңадан Гаделнең кабере янына, Згеж шәһәренә бардык. Анда Рөстәм үзенең улы белән хатынын да алып барды, рәсми кеше буларак язучы Габдрахман Минский безгә кушылды. Без анда бик күп очрашулар уздырдык, бик күп чыгышлар ясадык. Татарстан турында, Гадел Кутуй турында, татар әдәбияты турында сөйләдек. Соңыннан Польшадагы безнең илчелеккә чакырып безгә рәхмәт әйттеләр.

Гаделнең каберен рәтләп калдырганыма хәзер дә бик шатланам.

*1982, февраль*